ФАРАЗ ҺӘМ ӨМЕТ
«ВТ» хәбәрчесенең ил-көн вакыйгаларына күзәтүе
> 2

КАҺАРМАН ЮЛЫ
Аксубай районы Иске Кыязлы егетенең хыялы һәм вакытсыз өзелгән гомере турында
> 3

ЗӘҢГӘР ШӘЛ
Казан шәһәр филармониясе таныш әсәрне тагын бер кат хәтердә яңартты
> 4

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Адәм баласы үз гомеренә тулысынча хуҗа түгел»
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 185 (28958) | Чәршәмбе | 14 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТӨТЕНСЕЗ, ИССЕЗ КУРКЫНЫЧ

Сак булыгыз!

Татарстанда сөрем газы белән агуланучылар елдан-ел арта. Соңгы өч ел эчендә республикада газ чыгу нәтиҗәсендә килеп чыккан янгыннар саны 113кә җиткән. Шуларның 18е шартлау белән тәмамланган, 16 кеше һәлак булган. Белгечләр сак булырга, газ җиһазларын үз белдегең белән алыштырмаска киңәш итә.

– Салкыннар башлануга, өйләрне төрле газ җиһазлары белән җылытучылар табыла. Тик еш кына бу эш хәерле тәмамланмый. Хәтерләсәгез, 2021 елда Яшел Үзән һәм Чаллы шәһәрләрендә күңелсез хәлләр булды. Беренче очракта газ җиһазыннан дөрес файдаланмау, икенчесендә фатир хуҗасының үз белдеге белән шланг тоташтыруы аркасында килеп чыкты, – ди Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсе башлыгы урынбасары Максим Трущин.

Газ җиһазлары сак һәм игътибарлы булуны сорый. Максим Трущин аңлатканча, куллану җиһазының төзексез булуы, газ шлангларының дөрес тоташмавы, бүлмәдә җилләтү юлларының чистартылмавы да газ шартлауга сәбәп булып тора.

– Бигрәк тә газ баллоны еш шартлый. Аны күбрәк дача йортларында кулланалар. Мондый җиһаздан файдалануның аерым кагыйдәләре бар. Ни кызганыч, бу хакта белүчеләр сирәк. Газ баллонын металл шкафта сакларга кирәк. Аны ачык ут янәшәсендә һәм электр чыбыклары янында тотарга ярамый, – ди белгеч.

Газ баллоны уенчык түгел. Әгәр өйдә аз гына ис сизсәгез дә, аны бөтенләй кулланырга ярамый. Тагын шунысы да бар: җылыга кергәч, газның басымы күтәрелә. Шуңа күрә аеруча сак булырга кирәк. Газ янып торган җирдә тәмәке тартырга да ярамый.

«Газпромтрансгаз Казан» оешмасының генераль директор урынбасары Михаил Фролов та, газ җиһазларын дөрес куллану гына бәла-казадан саклап кала ала, дигән фикердә.

– Татарстанда 1,5 миллион газ кулланучы бар. Безнең хезмәткәрләр 2,5 миллион газ җиһазына хезмәт күрсәтә. Күңелсез хәлләрнең төп сәбәбе – газны дөрес кулланмау һәм һава йөрү системасының начар эшләве. Йортларын һәм фатирларын газ казаны белән җылытучылар өйдә һава йөрүне тәэмин итәргә тиеш. Техник хезмәт күрсәтүгә дә игътибарлы булсак иде. Газ җиһазларын вакытында белгечләргә күрсәтеп торырга кирәк. Бу эшне бары тик газ оешмасында эшләүче кеше генә башкара ала, – ди ул.

Максим Фролов быел сөрем газы белән агулануның 40 очрагы теркәлгәнне, 8 кеше үлгәнне дә әйтте. Әмма ул агулану очракларында газ җиһазларының төзек булганын да искәртте.

Шартлау һәм сөрем газы белән агуланулар булмасын өчен, нишләргә соң? Белгечләр иң элек кешеләрнең үзләренә битараф булмаска куша. Һәр кеше үз гомере өчен үзе җаваплы, ди алар. Йортың газ белән җылытыла икән, сиңа хезмәт күрсәтүче оешма белән килешү төзергә кирәк. Шәхси газ казаны булганнар бу килешүне аерым төзи. Ул бушка түгел, моның өчен елына ким дигәндә 3 мең сум акча түләргә кирәк. Тагын шул ягы да бар: газ казаны ватылса, хезмәт күрсәтүче оешма аны бушлай төзәтми. Акча әрәм була дип, кайчак үзебез әрәм булабыз да инде.

kzn.ru

Газчылар, техник хезмәт күрсәтергә килгәч, кешеләрнең өйләренә кертмәвеннән зарлана.

– Безне күпләр өйдә булып та кертми. Әллә ничә кат барырга, кесә телефоннарын табып шалтыратырга да туры килә. Юкса газ җиһазларының төзеклеге иң беренче чиратта аларга кирәк булырга тиеш, – ди газ җиһазларына хезмәт күрсәтүче оешма хезмәткәре Раил Исламов. – Күпләр өйләрендәге һава йөрү юлларын томалап бетерәләр. Газ чыгып ятса, алар аны үзләре белми дә кала. Шуңа күрә, махсус хезмәткәр килеп караса, яхшы инде. Без әллә нинди куркыныч эшләр башкармыйбыз. Плитәнең эшләү-эшләмәвен, газ чыгып ятмавын тикшерәбез, төтен һәм җилләтү юлларын да карап чыгабыз. Кышкы чорда йорт хуҗаларыннан аеруча уяулык сорала. Җиһазларны үз белдекләре белән тоташтырмасыннар, белгечләрне чакыртсыннар. Бер ялгыш адымның әллә никадәр гомерләргә зыян салырга мөмкин икәнен истән чыгармасыннар иде.

Соңгы вакытта газга бәйле фаҗигаләр арту сәбәпле, Россия Дәүләт Думасы депутатлары газ җиһазыннан файдалануга кагылышлы закон проекты да әзерләгән. Әлеге документ буенча, кулланучылар газ җиһазларыннан файдалануның куркынычсызлыгын тәэмин итүче оешмалар белән мәҗбүри рәвештә килешү төзергә тиеш булачак. Әлегә исә бу – һәркемнең үз иркендә.

Газ чыгып ятмасын өчен:
- өйдән чыкканда, газүткәргечтәге запас кранны да ябып куегыз;
- җиһазларыгызның төзексез икәнен күрсәгез, газчыларны чакыртыгыз;
- газ плитәсендә ризык әзерләнгәндә, аны караучысыз калдырмагыз.

Газ исе килгәндә:
- электр җиһазларын кабызмагыз һәм сүндермәгез;
- тәрәзәләрне, ишекләрне ачыгыз, газүткәргеч кранын ябыгыз;
- урамга чыгыгыз;
- 04 телефоны буенча (104 – кесә телефоныннан) газ хезмәтен чакыртыгыз.

Гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, коткаручыларга бердәм 112 телефоны буенча мөрәҗәгать итегез.

Ничек сакланырга?
- Өйләрдә газ чыгуны контрольдә тотучы сигнализатор урнаштырырга кирәк. Алар, метан һәм сөрем газы чыгуга, газ килү юлын автомат рәвештә ябып куя. Болай эшләү газ чыгуны, төтен һәм җилләтү юлындагы җитешсезлекләрне вакытында ачыкларга ярдәм итәчәк.

Соңдыр шул, соңдыр...

Россиядә гриппка каршы вакцинация эше тәмамланган. Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова әйтүенчә, хәзер прививка ясатырга соң инде һәм кирәкми дә. Барлыгы 74 миллионнан артыграк кеше прививка ясаткан. Илдә яшәүчеләрнең 52 процентын тәшкил итә бу. Татарстанда әлеге күрсәткеч – 46,8 процент.

Роспотребнадзор мәгълүматларына караганда, соңгы атнада илдә ОРВИ һәм грипп йоктыручылар саны 35 процентка арткан. Ведомство мәгълүматларына караганда, 37 төбәктә чирләүчеләр саны Россиядәге уртача күрсәткечтән арткан. Вирус йоктыручылар арасында һәр ике кешенең берсе грипптан чирли. Төмән өлкәсендә, Ямал-Ненец автономияле округы, Бурятия, Кострома, Вологда өлкәләрендә ОРВИ һәм грипп ияртү очраклары аеруча күп.

Тупланма югалмаячак

Пенсиянең тупланма өлешен дәүләтнеке булмаган Пенсия фондларында (НПФ) саклау өчен, фондның бөлгенлеккә төшү ихтималын күздә тотып, акчаны иминиятләштерергә тәкъдим иткәннәр. «Парламентская газета» язганча, Дәүләт Думасы утырышында шундый закон проекты икенче укылышта кабул ителгән.

Документ нигезендә, Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгында пенсиясенең тупланма өлешен НПФга күчерүчеләр өчен Пенсия резервларын гарантияләү фонды булдырылачак. Шулай итеп, НПФның бөлгенлеккә төшү яки лицензиясен алу очрагында, тупланма кешеләргә әнә шул Пенсия резервларын гарантияләү фонды хисабына кире кайтарылачак. Фондны НПФга түләүләр, төрле штрафлар һәм пенялар хисабына тулыландыру күздә тотыла.

Күбрәк түләячәкләр

Татарстанда айлык социаль юлда йөрү билеты, шул исәптән балалар өчен дә кыйммәтләнә. Аларның бәясе 6,2 һәм 6,3 процентка арта, дип хәбәр итә «Реальное время» басмасы.

Киләсе елда социаль «проездной» (аерым алганда, пенсионерларга, пенсия алды яшендәгеләргә бирелә) өчен аена 581 сум түләргә кирәк булачак. Быел аның бәясе – 547 сум. Димәк, 34 сумга кыйммәтләнә дигән сүз.

Балаларга айлык социаль юлда йөрү билеты хакы 21 сумга арта. Быел ул 333 сум торса, 2023 елда 354 сум тәшкил итәчәк. Яңа тарифлар киләсе елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә. Аларны Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы контрольдә тотачак.

Кәефне кырмасыннар

Белгечләр Яңа ел алдыннан мошенниклар кармагына эләгү куркынычы турында кисәтә. Интернет-кибетләрдә бүләкләргә заказ биргәндә аеруча сак булырга кирәк. Юкса, мошенниклар сайтына эләгеп, акчаны шуларга күчерү ихтималы бар.

Россиянең атказанган юристы Иван Соловьев RT хәбәрчесенә сөйләп үткәнчә, бәйрәмгә еш алына торган бүләкләр – йорт хайваннары, көнкүреш техникасы, сәгать, хәмер эчемлекләрен сатуда алдау очраклары аеруча күп күзәтелә. Шуңа күрә белгеч иң элек сатучыларның сайтларын игътибар белән тикшереп чыгарга, сәүдәгәрләр белән төрле мессенджерлар аша аралашуга кучмәскә киңәш итә.

Нәтиҗә

Яшь шәһәрнең серләре

ИННОПОЛИСТА ЯШӘҮ НИ ӨЧЕН РӘХӘТ?

Бу шәһәрдә яшәүчеләр үзләрен бик бәхетле дип саный икән. Бәхетне үлчәп булса, аларның бу күрсәткече 80 тирәсе булыр иде.

Уртача хезмәт хакы исә – 146 мең сум. Шәһәр буенча робот-такси йөри. Киләчәктә исә роботлы кунакханә ачарга исәпләре. Әкият иле түгел бу, 7 яшен тутырган Иннополис шәһәре турында сүз. Шәһәр үсешенә кагылышы булганнар журналистлар белән очрашып, узып баручы елга нәтиҗә ясады.

Татарстанның вице-премьеры Роман Шәйхетдинов әйтүенчә (Хөкүмәт дәрәҗәсендә Иннополис проектларының кураторы да ул. – **Авт.**), ел ахырына якынлашса да, шәһәрдә проектларны чынга ашыру, планнар кору тукталмый.

– Иннополис инновацион үзәге тотрыклы үсешен дәвам итә һәм цифрлы икътисад юнәлешендә федераль һәм республика проектларын гамәлгә ашыру, Россиянең бәйсезлеген тәэмин итә торган IT проектларны үстерү мәйданчыгы булып тора, – диде Роман Шәйхетдинов. – Биредә 2023–2024 елларга тәгаенләнгән 15 млрд сумлык зур инфраструктура-инвестиция проектлары һәм 2025 елга кадәр перспектив проектлар гамәлгә ашырыла. Без әле югарырак очар өчен тизлек җыя башладык кына.

Иннополиска җиде ел элек барган кеше белән хәзер баручылар сүзнең ни хакта барасын алдан ук чамалар. Ялан кырда калкып чыккан буш кала түгел инде ул күптән. Иннополиста хәзер робот-такси да бар, почтаны да робот ташый, халык гозерен социаль челтәрләр аша да хәл итәргә өйрәнгәннәр.

Шәһәр мэры Руслан Шәгалиев әйтүенчә, Иннополиста яшәүчеләр, авыз тутырып, үзләрен бәхетле дип әйтә ала. Бәхет күрсәткече биредә 80не тәшкил итә икән. Чагыштыру өчен: Россия буенча ул – 68.

Бәхетле булырсың да. Шәһәр халкының уртача хезмәт хакы гына да 146 мең сум икән. Мэр әйтүенчә, бу Татарстан буенча иң зур хезмәт хакы санала.

Иннополиста даими рәвештә 5 меңләп кеше яши. Гомуми халык саны – 7601. Калганнары – Казан, Яшел Үзән һәм бүтән якын-тирә шәһәрләрдән килеп-китеп йөрүчеләр. 2025 елга шәһәрдә даими яшәүчеләр саны 15 меңгә җитәр дигән өмет бар. Иннополиста яшәүче һәр өченче кеше һөнәре буенча йә галим, йә IT тармак белгече икән.

Яшь шәһәр булса да, Россия бюджетына ул салымны «зурларча» кайтара. Руслан Шәгалиев әйтүенчә, 2017 елда бюджетка күчерелгән салым һәм иминият кертемнәре 703,7 млн сум булса, 2022 елда бу сан биш мәртәбә артып, 3,6 млрд сумга җиткән.

Иннополис яңа технологияләр һәм хезмәтләрне сынау мәйданчыгы буларак та билгеле. Иннополиста 8 пилотсыз такси йөри. Иннополис үз территориясендә мондый мөмкинлек тудырган дөньяда икенче һәм Европада беренче шәһәр булып санала. Моннан тыш почта, кирәк-яракларны китереп бирә торган 15 роботлары бар икән. Һава аша да китереп бирү мөмкинлеген гамәлгә кертергә җыеналар.

Халык гозерен дә бот тыңлый. Исеме – Инна. Руслан Шәгалиев китергән мәгълүматларга караганда, виртуаль ярдәмчегә 2017 елдан алып 2022 елга кадәр 168292 мөрәҗәгать килгән.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Россия юлчылары төбәк автотрассаларында асфальт җәю буенча чираттагы рекорд куйды. Якынча 165 млн кв. метр юл түшәлде. Бу былтыргы күрсәткечтән бераз күбрәк. Аз булса да, алга китеш. Илдә заманча, сыйфатлы трассалар да, юлларның куркынычсызлыгы да, уңайлылыгы да артты.

(Илнең берничә төбәгендә яңа юллар ачу тантанасыннан)

ТАТАРСТАНДА – ЭШСЕЗЛЕК

Рәсми статистикага ышансаң, Татарстанда октябрь аенда 8,9 мең эшсез теркәлгән. 1691 кеше эшкә урнаша алган.

ЭШСЕЗЛЕК КҮРСӘТКЕЧЕ КАЙДА КҮБРӘК?
(Октябрь аена)

Түбән Кама (0,71%)	Әлмәт (0,52%)
Югары Ослан (0,68%)	Баулы (0,52%)
Алабуга (0,68%)	Нурлат (0,51%)
Казан (0,62%)	Саба (0,50%)
Әгерҗе (0,60%)	Теләче (0,47%)

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен — гадәти бәясе – ~~512 сум 70~~ тиен

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 980 сум 10 тиен — гадәти бәясе – ~~1143 сум 96~~ тиен

Реклама 16+

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ӘҖӘТЛӘР БАШТАН АШКАНДА

Дүшәмбедән сишәмбегә каршы төндә (аларда ул чакта көн бит инде) Америка телевидениесе гомум дөньякүләм әҗәтнең санын атады. Халыкара валюта фонды мәгълүматлары ул санның 235 триллион долларга җитүен күрсәтә. Санның масштабын чагыштырып карамыйча аңлау кыен.

Бөтен дөньяда җитештерелгән тулай продукт, мәсәлән, 127 триллион доллардан аз гына артык. Димәк, кешелек дөньясы, бурычлардан котылыйм дисә, ике елга якын җитештерелгән бар байлыгын бары тик әҗәт түләү өчен генә тотарга тиеш булыр иде. Кредитларның процентлы булуын да искә алсак, хәл тагын да мөшкелләнә. Бурычның төп өлешен түгел, процентын каплап бару кыенга әйләнә. Шуңа өстәп, дәүләтләр дә, хосусый бизнес та яңа әҗәтләр җыю хисабына гына алга бара. Бер яктан процентлар өстәлә, икенче яктан яңа кредитлар килеп ялгана. Без бүгенге дөньяда зур проблемалар, конфликтлар күзәтәбез икән, җепнең очы шул бурычлар бөҗрасына бәйләнгән.

Процент капиталы дәүләтләрдән бертуктаусыз эчке тулай продуктның үсешен таләп итә. Бурычка баткан бизнес һәм халыклар аны тәэмин итә алмый, чөнки продуктларны куллану мөмкинлеген әҗәтләр чикли. «Керемнәрдән әҗәт түлисеме, әллә яңа продукт сатып аласымы?» дигән дилемма килеп туа. Иске әҗәтне түләү өчен дә, продукт сатып алу өчен дә яңа әҗәтләр алырга туры килә. Яңа кредитлар тагын бер проблема китереп тудыра: инфляция мәйданга чыга. Без глобаль дөньяда шул хәлне күзәтәбез. Зур инфляция, җитештерүнең кимүе, рецессия… Без кризис дип атаган нәрсәләр шул инде. Рецессия эш урыннарын кыскарта, эшсез калганнар бурычларын түли алмыйлар. Яңа эш урыннары булдырыйк дип, хөкүмәтләр бюджеттан зур суммалар бүләләр. Ул акчаларны кредитка алырга туры килә. Дәүләт әҗәтенең астрономик суммалары шулай туа.

Үзәк банклар, инфляцияне киметү һәм кредитоманнар аппетитын чикләү өчен, төп ставканы күтәрә. Бу атнада Америкадагы ФРСның, Европа Үзәк банкының, Англия банкының, Швейцариянең Милли банкының утырышлары көтелә. Ваграк башка банклар да утырышка җыела, әмма дөнья финанс базарындагы хәлләрне шул дүрт банк чыгарган карарлар билгели. Алар исә төп ставканы 50 базис пунктка, ягъни 0,5 процентка күтәрергә җыена. Бердәм рәвештә шундый карарлар кабул ителсә, кредит алу отышсызга әйләнә. Фонд базарында акцияләр спекуляциясе дә файда бирми башлый. «Акчаң булса, депозитка салу яхшырак» дигән фикер өстенлек ала башлый. Фьючерс сәүдәсе дә зур табышлар вәгъдә итми. Бу безгә фонд базарының җимерелүен, чимал товарларга бәяләрнең төшүен, инфляция урынына дефляция вәгъдә итә. Кризисның кискенләшүен аңлата бу. Үткән атнада болай да фонд базарлары нигездә кызыл зонада булды, ягъни кәгазьләрнең бәясе төште. Нефть арзанайды. Икътисад паровозы, шаулап, классик кризис зонасына кереп бара. Аннан чыгу өчен, төп ставкаларны төшереп, күпләп кредит өләшергә кирәк булыр иде, әмма моңа югарыда аталган глобаль әҗәтнең астрономик суммасы комачаулый. Бу гамәлдәге системада кризистан чыгып булмый дигәнне аңлата, системаны алыштыру таләп ителә. Система алышынганда, ниләр булганын социалистик системаның җимерелүен үз җилкәсендә татыган безнең буын яхшы хәтерли әле.

Россиядә

ҺИНД ТОЗАГЫНА ТӨШКӘН ИКЪТИСАД

Германиянең федераль канцлеры Шольц: «Украинадагы сугыш хәрәкәтләре хәл ителсә, Россия Германия белән эшлекле мөнәсәбәтләрен торгыза алыр иде», – дигән белдерү ясады. Шольцның сагышы аңлашыла, чөнки бизнес – җинаятьчелек кебек үк, интернациональ күренеш ул. Дус илләрнең кайсына да булса килеп төшәсең икән (дус булмаганнарга безне бик кертмиләр бит инде), эшмәкәрләрне синең милләтең, кайсы илдән килгән булуың бик кызыксындырмый, кесәңдәге акчаң мөһимрәк.

Риелторлар, әйтик, синә фатирны кыйбатка арендага биреп яисә сатып кинәнәчәк, банкирлар синең үзләрендә хисап ачуыңа сөенәчәк һәм башкалар. Җирле халык бик сөенеп китмәс, бәлки, әмма бизнес кочагын җәячәк. Үткән тәүлекләрдә генә американнар Казахстанга «Мир» карталары белән эшләргә рөхсәт иттеләр. Бу – шиксез, Токаев дипломатиясе нәтиҗәсе. Казахстан Президенты исә илгә Россия капиталы күбрәк килсен дип тырыша. Шольц та шулай ук. Немец товарлары белән Россия базарына үтеп керә алса, арзанлы нефть һәм газга тиенсә, Германия үз икътисадын берникадәр вакытка булса да упкыннан тартып чыгара алачак. Ил лидерына тагын ни кирәк?!

Россиягә кертелгән санкцияләрнең мәгънәсе дә шунда: Мәскәү өчен базарларны тарайтып, аны аяктан егу. Соңыннан, егылган илгә үз ихтыярыңны тагып, базарын яулап алу кыен түгел.

Азия базары белән генә чикләнү Россиягә зур проблемалар тудыра, моны танымыйча булмый. Әйтик, Һиндстан белән сәүдәне генә алыйк. Әйе, бездә шундый сөенеч бар: Көнбатыш алмаса, безнең нефтьне моңарчы алмаган индуслар күпләп ала. Ни аерма бар? Кызганыч, бар шул. Бердән, Азия гигантлары бездән «кара алтын»ны бик зур ташлама белән ала. «Демпинг» дигән нәрсәдән файдаланмый булмый. Бу башка көндәшләрне базардан этеп чыгару өчен бәяләрне чамасыз төшерүне аңлата. Россиянең Азия базарларында җир маен демпингка сатуы Якын Көнчыгыштагы нефть державаларының ачуын китерә башлады инде. Бу озак сроклы перспективада гарәпләр белән конфликт килеп чыгу мөмкинлеге турында сөйли.

Әмма эш анда гына да түгел. Индуслар бездән чималны рупиягә сатып алуны алга сөрәләр. Мәскәү, башка базарлар тапмагач, килешергә мәҗбүр. Рупия исә – бик йомшак валюта. Аның бер дә дәрәҗәсе юк. Соңгы ике елда ул сумга карата 25 процентка очсызланган. Болай да арзанга сатасың, валюта йомшарып, аны тагын да арзанайта. Эш моның белән генә дә төгәлләнми әле. Һиндстанга Россия экспорты күләме алардан без импортлаганга караганда берничә тапкыр артык. Артык рупияләрне кая куясың? Беркемгә дә кирәкми, бернигә дә ярамый торган кәгазьләр белән банклар тула. Һиндстаннан товар сатып алуны арттырырга мөмкин, әлбәттә. Әмма, белгечләр әйтүенчә, товар әйләнешен барыбер баланслап булмаячак. Ноябрь аенда индуслар диңгез аша сатылган Россия нефтенең 40 процентын сатып алганнар икән. Кытай, мәсәлән, 5 процентын гына. Стратегик чималны тагын файдасыз кәгазьгә сатабыз бит.

КҮРЕШЕРГӘ ЯХШЫ СӘБӘП БАР

Казахстан Президенты Касыйм-Җомарт Токаев белән очрашкач, Рөстәм Миңнеханов әнә шулай диде. Бу илдә өр-яңа шин заводы эшли башлады. Бу – ике республиканың уртак проекты.

tatarstan.ru

Татарстан Президенты, Төркиягә сәфәр кылганнан соң, Казахстанга юл тотты. Анда ул бу ил Премьер-министрының беренче урынбасары Роман Скляр белән «KamaTyrezKz» заводында тәүге автомобиль шинын җитештерү тантанасында катнашты. Завод Караганда өлкәсенең Сарань шәһәрендә урнашкан. Бу – безнең «Татнефть» һәм казахларның «Аллюр» компанияләр төркеме»нең уртак проекты. Тантаналы чарада Рөстәм Миңнеханов Россия Федерациясе һәм Казахстан Республикасы җитәкчелегенә Татарстан – Казахстан хезмәттәшлеген үстерүдә һәм уртак проектны тормышка ашыруда ярдәм итүләре өчен рәхмәт белдерде. «Казахстан – Татарстанның әйдәп баручы чит ил партнерларының берсе. Ике арадагы хезмәттәшлекнең елдан-ел киңәюенә шатбыз», – диде ул.

«KamaTyrezKz» – Казахстанда автомобиль шиннары җитештерү буенча тәүге завод. Моңарчы мондый продукцияне тулысынча чит илләрдән, шул исәптән Татарстаннан сатып алырга туры килгән. Завод төзелешенә 2001 елда старт бирелде. Ул киләсе елда тулы көченә эшли башлар, дип көтелә. Уртак проектның икенче этабында – резина-техник эшләнмәләр җитештерә башлау, өченче этапта исә авыл хуҗалыгы техникасы өчен шиннар чыгару күздә тотыла. Эш заманча технологияләргә нигезләнгән, шуңа күрә әзер продукция сыйфаты ягыннан дөнья күләмендә иң яхшыларыннан берсе булып саналачак, диләр. Проектка инвестицияләр күләме якынча 22,7 миллиард сум тәшкил иткән. Заводта елына 3 миллион җиңел һәм 500 мең йөк машинасы шины эшләп чыгара алалар. Яңа эш урыннары да артачак. Биредә 1 меңнән артык белгечкә эш урыны бар. Әзер продукцияне чит илләргә озатырга да ниятлиләр.

Яңа завод ике ил икътисадын тагын да ныгытачак. Уртак эшчәнлекнең нәтиҗәсе дә күз алдында. Быел тугыз айда ике арада сәүдә әйләнеше 467 миллион доллар тәшкил иткән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, үсеш – 6 процент.

Уртак проектның әһәмияте турында Рөстәм Миңнеханов һәм Касыйм-Җомарт Токаев Астанада узган очрашу барышында да сөйләштеләр. «Бу – күрешү өчен яхшы сәбәп!» – диде Рөстәм Миңнеханов, завод ачылу тантанасына ишарәләп. Аның әйтүенчә, мондый уртак проектлар Россия һәм Казахстан арасындагы эшлекле мөнәсәбәтләрне ныгыта. «Безгә булган игътибарыгыз һәм уртак проектларны тормышка ашыруда ярдәмегез өчен рәхмәт», – диде Рөстәм Миңнеханов. Казахстан Президенты ике арадагы хезмәттәшлекне үстерүнең әһәмиятен билгеләп үтте. Ул алга таба да уртак проектларны гамәлгә кертүдә ярдәм итәргә вәгъдә бирде.

Мәдәни нигез нык булсын

Идел буе төбәкләренең закон чыгаручылары мәдәният турында фикер алышты. Федераль округ субъектлары дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары ассоциациясенең Йошкар-Олада узган утырышында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Утырыш кысасында Россия Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров Фәрит Мөхәммәтшинга Александр Невский орденын тапшырды. Россия Президенты Владимир Путин шул хакта Указны 14 ноябрьдә имзалады. Фәрит Мөхәммәтшин югары дәрәҗәдәге бүләккә Россия дәүләтчелеген ныгытуга, Россия парламентаризмын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм законнар иҗат итү эшчәнлеген актив төстә алып баруы өчен лаек булган.

Игорь Комаров, ассоциация утырышын ачып, халык тормышын яхшыртуның барлык хакимият органнары өчен өстенлекле бурыч булып калуын, шул ук вакытта мәгариф һәм мәдәниятнең социаль «кәеф»не билгеләүче мөһим өлкәләр булып торуын билгеләп үтте. «Округның барлык төбәкләрендә «Мәдәният» илкүләм проекты кысасында күп чаралар үткәрелә, мәдәният объектларын төзү һәм капиталь төзекләндерү эшләре алып барыла. Балалар сәнгать мәктәпләре музыка кораллары, заманча җиһазлар белән тәэмин ителә, китапханәләр һәм виртуаль концерт заллары булдырыла. «Пушкин картасы» проекты тормышка ашырыла. Без, бергәләшеп, күп кенә тәкъдимнәр булдырдык, аларның барысы да Россия Мәдәният министрлыгына җибәреләчәк», – диде Игорь Комаров. Әйтергә кирәк, ассоциация утырышында мәдәният мәсьәләләренең аерым игътибарга алынуы очраклы гына түгел, чөнки быел илдә Россия халыкларының мәдәни мирасы елы игълан ителде.

«Мәдәни мохит» төбәк проектлары ил субъектларында яңа мәдәният корылмалары төзү, искеләрен реконструкцияләү мөмкинлеге бирә. Татарстанда быел гына да биш авылда мәдәният йорты калкып чыкты. Мәдәни үсеш үзәкләре һәм модаль китапханәләр ачылды. Район һәм шәһәрләрнең сәнгать мәктәпләре, муниципаль музей-театрлар төзекләндерелде. Якын араларда Түбән Камада, төзекләндерелгәннән соң, яшь тамашачы театры ачылачак. Быел Татарстанда «Мәдәният» илкүләм проектын тормышка ашыруга 1,2 миллиард сум чамасы акча сарыф итү күздә тотылган.

«Мәдәният, традицион кыйммәтләрне саклау мәсьәләләре һәрвакыт өстенлекле булып килде. Бүген, махсус хәрби операция шартларында илебез Көнбатыш илләре басымына дучар булган бер мәлдә, алар аеруча мөһим, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Күпкырлы икътисадка ия булган күпмилләтле төбәкләргә аеруча кагыла бу».

Идел буе төбәге закон чыгаручылары фикер алышу йомгаклары буенча кайбер тәкъдимнәр белән чыкты. Аерым алганда, Россия Хөкүмәтенә «Мәдәният» илкүләм проектын тормышка ашыру вакытын 2030 елга кадәр озайту, авылларга эшкә кайтучы мәдәният хезмәткәрләренә ярдәм итү буенча «Авыл мәдәният хезмәткәре» федераль программасын кабул итүне тизләтү, «Пушкин картасы» программасында катнашучылар исемлегенә циркларны да кертүне тәкъдим иткәннәр. Моннан тыш парламентчылар «Мәдәни мохит» федераль проектына заманча янгын куркынычсызлыгы таләпләренә һәм санитария нормаларына туры килердәй яңа сәнгать мәктәпләре биналарын төзүне кертү мәсьәләсен күтәргән.

«Бүгенге утырышка кертелгән мәсьәләләр бик мөһим, – диде Фәрит Мөхәммәтшин журналистларга. – Мәдәни мирасны саклау, Идел буе федераль округында яшәүчеләрнең мәдәни үсеше өчен матди базаны ныгыту, белем алу мөмкинлекләре… Янә яшьләрне ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү мәсьәләләре күтәрелде. Татарстанда бу юнәлешләргә зур игътибар бирелә».

Ассоциация утырышында Татарстан Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентының Административ хокук бозулар турында Россия кодексына балигъ булмаганнарга татуировкалар ясауга бәйле статьяны өстәү тәкъдиме хупланды.

Яшь шәһәрнең серләре

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Мэр яшь каланың киләчәген матур итеп күрергә тели. Планнары да зурдан. Әйтик, 53 номерга исәпләнгән роботлы кунакханәне төзеп бетерергә ниятлиләр. Шәһәр эчендәге яңа таунхаусны кулланышка тапшырмакчылар. 3500 фатирга исәпләнгән «Ю» торак кварталын төзергә җыеналар. Яшәр урыны булгач, мәктәбе, балалар бакчасы, парклары да кирәк. Мэр әйтүенчә, 900 урынлы мәктәп, 600 урынга исәпләнгән балалар бакчасын сафка бастырмакчылар. Шулай ук балалар сырхауханәсе дә барлыкка киләчәк.

– Шунысын да әйтергә кирәк: Иннополиста арендага бирелә торган тораклар калмады. Махсус икътисадый зонада эшләүчеләр «Салават Күпере»ндәге фатирларда яши, – диде ул.

Университет эшчәнлеге

Иннополистагы һәр өченче кеше галим йә IT тармак белгече дидек инде. Аларны укыту биредә үк башкарыла. Уку йорты директоры Кирилл Семенихин әйтүенчә, берничә көн элек кенә университет 10 еллыгын билгеләп үткән. Бу вакыт аралыгында «акыллы баш»ларны әзерли торган белем йорты алга китеш кичергәнме соң?

– Университетта, база белеме бирүдән тыш, өстәмә укыту да бар. Дистә ел эчендә университет 448 индустриаль проектны гамәлгә ашырды. Университетның еллык акча әйләнеше 6 млрд сумны тәшкил итә. 2030 елга 15 млрд сумга җитәргә исәп, – дип уртаклашты Кирилл Семенихин.

Аның сүзләренчә, Иннополис университеты кысасында берничә федераль белем бирү үзәге эшли. Әйтик, инженерия мәктәбе, ясалма интеллект, инновацияләр, робототехника үзәге.

Киләсе елга исә 1 мең урынга исәпләнгән яңа торак корпусны кулланышка тапшырырга исәп. Тагын бер лаборатория эшләтеп җибәрергә җыеналар (әлегә аларның саны 17. – **Авт.**), укыту юнәлешендә яңа белем бирү программалары өстәргә телиләр.

Тагын да зуррак хыялларга килсәк, алар арасында студентлар санын 5 меңгә кадәр җиткерү, компьютер фәне буенча дөньяның иң яхшы университетлары исемлегенә керү, индустрия үзәген булдыру кебекләре бар.

Махсус икътисадый зона эшчәнлеге

Вазгыять җиңел булмаса да, «Иннополис» махсус икътисадый зонасына быел 66 компания кушылган. Хәзер зонада эшчәнлек алып барган резидентлар саны 336га җиткән. «Иннополис» махсус икътисадый зонасы директоры Ринат Хәлимов әйтүенчә, сынаулар булса да, үсеш күзәтелә.

– Инвестицияләр күләме 73,8 млрд сумны тәшкил итә, керем күләме – 130,3 млрд сум. Бюджетка җыелган салым күләме – 19,9 млрд сум, – дип вазгыятьне сан теләндә аңлатты ул.

«Күп өлкәләрдә кимү күзәтелгәндә, артуга ирешү мөмкинме?» дигән сорауга да алдан җавап бирде Ринат Хәлимов.

– Махсус икътисадый зонада барлык күрсәткечләрнең уңай динамикасын саклый алабыз. Бу ни өчен шулай? Нигездә, Иннополиста урын алган компанияләр – Россиянеке. Алар Россия өчен кирәкле эшләнмәләр уйлап таба иде. Соңгы биш елда башкарган эшләргә хәзер аеруча ихтыяҗ артты. Шуңа да күпчелек компанияләр үсештә. Компанияләрнең якынча 3 проценты чит илнеке иде, – дип аңлатты ул.

Киләчәк турында сөйләгәндә, Ринат Хәлимов үзләрендә зурдан кубып башкарылачак эшләрне телгә алды. Әйтик, «Иннопарк» югары технологияләр җитештерү үзәге, мәгълүмат эшкәртү үзәге, «Родина» технопаркы, сәнәгать инновацияләре паркы. Моннан тыш Россия өчен компьютерның төп платосын җитештерү проектын да тормышка ашырырга хыялланалар. Аны елына 1 млн данәдә җитештерү максаты тора.

Кызыгып һәм кызыксынып

Шәһәр мэры Руслан Шәгалиев әйтүенә, Иннополиска туристлар да эз суытмый. Үзе дә күрсәтеп, аңлатып, таныштырып йөрергә әзер ул. «Бер ел элек булган шәһәр белән хәзергесе арасында аерма бар. Килеп күрергә генә кирәк. Халыкта ялан кырда утырган шәһәр дигән калыплашкан фикер яшәмәсен иде», – диде ул.

Журналистлар очрашуга килүчеләрдән: «Иннополис сезнең өчен нәрсә ул?» – дип тә кызыксынды.

Роман Шәйхетдинов өчен ул шәһәр генә түгел, бәлки, тормыш рәвеше дә икән әле. Руслан Шәгалиев исә, булганы белән канәгатьләнеп калмыйча, тагын да югарырак үрләргә ирешәсе иде, ди. Шәһәрне, чынлап та, әкият иле һәм мөмкинлекләр мохите итмәкче бугай.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЧЫКМАСЫН ИС!

Табигать сагында

Миллионнар түләп төзелгән чистарту корылмалары ярты ел эчендә сафтан чыккан. Питрәчтә һәм Кощаково бистәсендә, Алексеевскида, Әгерҗенең Красный Бор авылындагы биологик су чистарту корылмаларыннан чыккан суның тиешле таләпләргә туры килмәве ачыкланган. Әлеге корылмаларның күбесе «Экология» илкүләм проекты кысасында яңа гына төзелгән.

Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Росприроднадзор) Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе Фаяз Шакиров сөйләде.

– Питрәч һәм Алексеевск районнарында чистарту корылмаларын карап торучы оешмалар билгеле булса, Әгерҗе, Яшел Үзән, Зәй районнарында аларның хуҗасы юк. Питрәч районындагы корылма өчен җаваплы оешмадан сулыкларга килгән зыянны арбитраж суды аша түләтәчәкбез. Бу корылмалар федераль акча ярдәме белән төзелә, – диде идарә җитәкчесе. – Әлегә төгәл нәтиҗәләр булмаса да, агып чыккан суда калдыкларның нормадан унар мәртәбә артканы күренеп тора. Елгаларга эләккәнче, су тиешенчә чистартылырга тиеш. Тиешенчә эшләнмәгән корылмалар озакка чыдамый. Күпме акча тотып төзелгән чистарту җайланмасы ярты елда эштән чыга. Аларны карап торырлык белгечләр җитми. Ә бит төзәтү бик катлаулы. Без закон бозылуны күрәбез икән, штраф салабыз, килгән зыянны түләтәбез.

Быел Татарстанда әйләнә-тирәгә зыян салган 443 закон бозу очрагы теркәлгән. Гаепләләргә 56 миллион сумлык штраф салынган.

– Март аеннан күзәтчелек органнары тарафыннан алдан планлаштырылган тикшерүләрне бетерделәр. Әмма безгә оешмаларның ачык территорияләренә керү тыелмаган. Күптән түгел бер оешмага кердек. Анда шлагбаум да юк. Ни күрик: алар шул урында калдыкларны күмеп ятканнар. Биредә табигатькә бик зур зыян салынган. Шуңа күрә быелгы штраф күләме әле тагын да артырга мөмкин, – ди Фаяз Шакиров.

Тикшерү дигәннән, халык Казан һәм Түбән Кама шәһәрләрендә эшләүче 6 сәнәгать оешмасыннан зарланып мөрәҗәгать иткән.

– Быел һаваның пычраклыгыннан зарланып язылган 60 мөрәҗәгать алдык. Барысын да табигатьне саклау прокуратурасына юлладык. Хәзерге көндә тикшерүләр башланды, – ди Фаяз Шакиров. – Элегрәк Түбән Камада һаваның пычрак булуыннан зарланып көненә хәтта 300-400 тапкыр мөрәҗәгать итәләр иде, хәзер андый очраклар берән-сәрән генә. Анда һәрдаим Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы күчмә лабораторияләренең эшләве дә уңай нәтиҗә бирә. Сүз уңаеннан, Түбән Камада Татарстан буенча Лаборатория анализы һәм техник үлчәү үзәге ачарга җыеналар. Ул 443 күрсәткечне исәпкә алачак.

Әйләнә-тирәгә зыян салучылар саны кимесә дә, зарланучылар аз түгел, ди Фаяз Шакиров. Халыктан килгән мөрәҗәгатьләр арасында газ исеннән зарланучылар да бар. Газ исе калдыклардан да чыгарга мөмкин икән. Моннан берничә ел элек Казанның Самосырово чүплегеннән начар ис таралып ятканын күпләр хәтерли.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Восточный» полигонында җыештыру эшләрен тотынып, аны рекультивацияли башлагач, зарлар кимеде. Хәзер исә истән «Салават Күпере»ндә яшәүчеләр зарлана.

Очрашуда сәнәгать оешмаларының табигать законнарын бозуы гына түгел, ялган хисап тотулары хакында да сүз булды. Баксаң, кайберләре экологик контроль алып бармаса да, кирәкле белешмәне табалар икән. Татарстанда оешмаларга ялган документлар бирүче лабораторияләр дә барлыгы ачыкланган. Фаяз Шакиров андыйларны табарга һәм чарасын күрергә кирәк дип саный. Шундый өч лабораториянең эзенә төшкәннәр инде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ОЧЫП КИТЕП БАРДЫ...

КАҺАРМАН ЯКТАШЫБЫЗ ГЕРМАН ЗАХАРОВНЫҢ ТОРМЫШ СӘХИФӘЛӘРЕ

Батырлар

Аксубай районы Иске Кыязлы авылында туып-үскән малайның балачак хыялы була бу. Бары тик үз тырышлыгы, үҗәтлеге белән тормышка да ашыра ул аны.

Ана күңеле

Ни кызганыч, гомере кыска була Германның.

– 24 февраль көнне иртүк киленебез Карина шалтыратты, – дип искә ала әнисе Людмила Сергеевна. – Герман Кырым Республикасындагы Джанкой шәһәрендә урнашкан хәрби частьта хезмәт итә иде. Киленебез шунда яши. Хәрби операция турында ишеткәнбезме-юкмы – шуны беләсе килгән, күрәсең. Башта сораштырды. Аннан: «Анда өйрәнүләр генә бара. Барысы да әйбәт булыр», – дигән булды. Тик ахыр чиктә Германның да шунда икәнлеген барыбер әйтмичә түзә алмады. Хәер, мин ул шалтыраткач ук сизенгән идем инде. Юкка гына хәрби операция турында сүз башламады бит. Ана йөрәген алдалап буламыни?! Моңа кадәр дә командировкаларда күп булды Герман. Кая җибәргәннәре, андагы хәлләр турында беркайчан да сөйләмәде. Шалтыратса да, барысы да әйбәт, дип ике сүз генә әйтә иде. Смс язса да, шуннан артмады. Сораша башласак, бик тиз туктатты. Бу арада элемтәгә чыгып булмас, 2–3 көннән үзем шалтыратырмын, дип кисәтеп куярга да онытмады. Кыскасы, безне бер дә борчырга теләмәде. Күнегеп булмаса да, без бу хәлләрне ничектер үзебезчә кабул итәргә өйрәнгән дә идек инде.

8 мартта төштән соң Герман хезмәт иткән частьтан шалтыратып: «Улыгыз очкан вертолетны бәреп төшергәннәр. Кайда икәнлекләрен белмибез», – дип хәбәр иттеләр. Экипаж составында өч кеше – пилот, бортчы һәм штурман. Герман өлкән лейтенант званиесендә, штурман иде. Ул вакытта алар заданиегә бер эскадрилья – дүрт вертолет бергә очканнар. Әйләнеп кайта алмаганнар… Безнекеләр тулы составта хәбәрсез югалган дип исәпләнгән, ә калган экипажлардан частька кайтучылар да, әсирлеккә эләгүчеләр дә, хәбәрсез югалганнар да булган. Шул вакыттан бирле көне-төне берәр хәбәр көттек. Хәрби часть белән гел элемтәдә тордык. Әлбәттә, ышанып җитмәсәк тә, яхшыга өметләндек. Әмма 22 сентябрьдә күңелнең иң тирән җирендә пыскып торган өмет киселде…

Безне Ростовка чакырдылар. Әтисе Василий белән бергә киттек. Джанкойдан киленебез килде. Карина педагогия институтында өченче курста укый. Ярты ел гына бергә яшәп калдылар. Ул вакытта без дә Кырымга туйга барган идек. Коронавирус булганлыктан, бәйрәмне әллә ни зурлап үткәрмәделәр. Яңа туганнарыбыз белән очрашып, аралашып кайттык. Герман белән соңгы күрешүебез дә шунда булган икән.

Ростовта безне тиешенчә каршы алдылар. Германны танып белергә ирем белән икәү кердек. Улыбызның кесәсендә машина, фатир ачкычы бар иде. Карина шундук үзләренеке икәнен танып алды. Шуңа да ДНК анализларын ясаганчы ук аның Герман булуына бернинди дә шик калмады. Вертолетны Николаев өлкәсенең Калиновка авылы



янында бәреп төшергәннәр. Аннан соңгы хәлләр ничек булгандыр, бу хакта безгә берни дә сөйләмәделәр. 3 август көнне алмашу максатыннан экипаж составындагы хәрбиләрнең мәетләрен үзебезнекеләргә тапшырганнар. Алып кайтып, авылыбыз зиратына җирләдек. Район җитәкчеләре дә, хәрби комиссариатныкылар да бик кадер-хөрмәт күрсәттеләр. Җирле үзидарәдә эшләүчеләр, авылдашлар, мәктәп балалары – барысы да булыштылар. Рәхмәт үзләренә. Онытмадылар, шунысы күңелне сөендерә. Үзебез өчен дә, авылдашлар, дус-туганнары өчен дә Герман – чын каһарман, туган илен, туган җирен саклаучы үрнәк кеше. Укучылар аңа багышлап аерым бер почмак ясап куйдылар. Мәктәп янәшәсенә истәлек тактасы элделәр. Күңелгә бик авыр булса да, горурлык хисе барыбер ташламый. Беркайчан да бирешмәде, сыгылып төшмәде, кешелеген җуймады, батыр булды улыбыз.

Горурлык

Мәктәптә батыр якташларына шундый зур игътибар бирүләре юкка гына түгел. Нәкъ менә шушында канат ярган, хыялын тормышка ашырырга юл тапкан укучы бит ул.

– Минем очасым килә, дип бәләкәйдән аптыратып йөрде, – дип искә ала Людмила Сергеевна. – Баштарак, сабый бит әле дип, игътибар да итмәгән идек. Әмма тора-бара бу хыялның барыбер тормышка ашачагына төшендек. Әзерләнә торсын дип, 6 нчы сыйныфка Түбән Камадагы кадетлар мәктәбенә керттек. Тик бер ай укыдымы-юкмы икән, чирләп китте. «Өйгә кайтасың киләме?» – дип сораган идек. Килә, диде. Бала бит инде, җитмәсә, хәле дә әллә ни түгел иде. Алып кайттык. Яңадан берәр нәрсә килеп чыкмасын дип, үзебезнең янда гына калдырырга булдык. Шуннан соң ничектер улымның бу хыялы сүнгән кебек тоелган иде. Искә дә алмады, сөйләмәде дә кебек. 10 нчы сыйныфка җиткәч: «Улым, укырга кая китәрсең икән?» – дип үзем сүз башладым. Ул миңа гаҗәпләнеп карап торды да, болай да беләсез бит инде дигәндәй: «Вертолетта очарга өйрәнергә инде», – дип куйды. Шулай итеп, укуны тәмамлагач, Сызраньдагы хәрби авиация училищесына китеп барды. «Очучы була алмасам, инженер һөнәрен үзләштерермен, вертолетлар төзәтермен», – диде. Беребез дә каршы килмәдек. Хәер, ул барыбер үз дигәнен эшләгән булыр иде. Училищеда укуын тәмамлагач, тагын бер гаҗәеп таланты белән гаҗәпләндерде: бик матур картиналар иҗат итә башлады.

Апасы Вера белән аралары 11 ай гына, Герман 1996 елда туган. Мәктәптә дә бер сыйныфта укыганнар.

– Герман күпкә яхшырак укыды. Миңа начаррак билге куйсалар, үземә караганда да ныграк кайгыра иде, – ди Вера. – Бик дус идек без аның белән. Яхшы укыгач, мин генә түгел, сыйныфташлар да аннан гел ярдәм итүен үтенделәр. Ә болай, башкалар кебек үк гап-гади малай иде ул. Машинада йөрергә бик кызыкты. Җай туры килгән саен, рульгә утырырга карый иде. Әмма очу аның төп теләге булды. Авылда әллә ни майтарырга мөмкинлекләр юк, түгәрәкләр дә эшләми, шуңа күрә беренче чиратта сәламәтлеген ныгытырга, спорт белән шөгыльләнергә тырышты. Хәер, авыл баласының көндәлек тормышы үзе спорт иде инде ул. 4 нче сыйныфтан соң күрше авылга, җиде чакрым ераклыктагы Яңа Тимошкино мәктәбенә йөреп укыдык. Кыш көне чаңгыга бастык. Йорттагы физик көч сорый торган эшләр дә энем җилкәсендә булды. Нык булып үсте ул, чын егет булып җитеште. Бары тик хәрби кеше булырга хыялланды. 10 нчы сыйныфта укыганда документлар җыя башлады. Бик күп медицина комиссияләре үтәргә туры килде аңа. Башка уку йортлары турында хәтта уйлап та карамады. Мин, аптырагач, кирә алмаса, бөтенләй утырып калмасын инде дип, документларының күчермәләрен Казанга, КАИ белән КХТИга илтеп бирдем. Хәтта кабул итү комиссияләренә дә үз телефон номерымны калдырырга туры килде. Икесенә дә үтте. Документларыгызны алып килегез, дип шалтыраттылар. Ә Герман минем бу тырышлыкларыма кулын гына селтәде. Күрәсең, үзенең һичшиксез хәрби училищега керәчәгенә ышанган иде. Елына ике тапкыр чираттагы ялларын да гел авылда үткәрде энем. Әти-әнием икесе дә – эш кешеләре. Әтием – сак хезмәтендә, әнием – китапче. Герман алар өчен төп таяныч булды. Училищеда укыган елларында Самара шәһәрендә Җиңү көненә багышланган хәрби парадта катнашты. Шунда Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан медаль белән бүләкләделәр. Энем бик аз яшәп калды, әмма ул үзенең кыска гына гомерен Ватаныбызны саклауга багышлады, үз алдына куйган тормыш кагыйдәләреннән бер адым да читкә тайпылмады.

…Людмила Сергеевнаның исә бер теләге бар.

– Тынычлык урнашкач, улым һәлак булган җиргә, Калиновка авылына барып кайтырга хыялланам. Авыл халкы арасында күрүчеләр, бу хәл турында белүчеләр бар дип уйлыйм. Алар белән сөйләшер, аралашыр идем. Бу гамәл йөрәгемә тынычлык иңдерерме – белмим. Әмма улымның язмышын ачыклыйсым килә, – диде ул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

СЕЗ ИҢ КИРӘК КЕШЕ ИКӘНСЕЗ...

Татарстанга 96 агроном, 73 зоотехник, 133 ветеринария табибы, 69 инженер һәм 760 (!) механизатор кирәк. Бу саннарны авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Марсель Мәхмүтов җиткерде. Аның сүзләренә караганда, авылга 3 меңләп белгеч җитми.

– Шәһәргә укырга китүче яшьләрнең күбесе, кызганыч, кире авылга кайтырга теләми. Бүген агросәнәгать комплексы һәм икътисад өлкәсендә 70 меңнән артык кеше хезмәт куя. Тик республика кадрларга кытлык кичерүен дәвам итә, – ди министр урынбасары. – Министрлык эшче һөнәрләргә кадрлар җәлеп итү буенча төрле чаралар күрә. Әйтик, югары уку йортларын тәмамлаучы яшь белгечләргә – 300 мең сум, техникумнарны тәмамлаучыларга 150 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие түләү каралган. Ел дәвамында хезмәт хакына 7500 сум күләмендә айлык өстәмә түләү дә бар.

Эштән тыш, яшь аграрийларга торак мәсьәләсе дә мөһим. 2020 елдан республикада «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» федераль дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. Аның буенча эшче яшьләр социаль түләүләр, наемга торак һәм яшьләр арасында аеруча популяр булган авыл ипотекасын ала алалар.

Татарстан яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары Ринат Садыйков яшь гаиләләргә торак шартларын яхшырту өчен ярдәм итү чаралары турында әйтеп узды.

– Күпбалалы яшь гаиләләр өчен торак шартларын яхшырту буенча федераль программа эшли. Без ел саен 50дән артык гаиләгә торак алу өчен түләүсез дәүләт ярдәме күрсәтәбез. Киләсе елда мондый ярдәмне 70тән артык гаилә алачак. Аларның 70 процентка якыны – авыл, район үзәкләрендә яшәүче гаиләләр, – диде ул.

Авыл хуҗалыгында эшләүче яшьләрне кызыктыру ниятеннән Татарстанда ел саен «Һөнәре буенча иң яхшысы» республика һөнәри осталык конкурсы оештырыла. Быел ул 21–22 декабрьдә уза. Бәйгедә 18–35 яшьлекләр катнаша ала. Аларның кимендә бер еллык эш тәҗрибәсе булырга тиеш. Хисапчылар өчен бу – 5, ә ветеринария табиблары һәм агрономнар өчен – кимендә 3 ел. Узган ел бәйгедә катнашу өчен 363 гариза килгән. Призлы урыннарны алучылар 10, 8 һәм 6 мең сум күләмендә акча белән бүләкләнәчәк. Беренче урынны яулаучылар чит илләрдә яки ил төбәкләрендә стажировка узу мөмкинлегенә ия булачак. «Әлеге бәйгедә катнашучы яшь һәм актив белгечләрне күзәтеп, без агросәнәгать комплексының киләчәге бар икәнен күрәбез», – ди Марсель Мәхмүтов.

Әлеге бәйгенең «Иң яхшы машина белән сыер саву операторы» номинациясе җиңүчесе Анна Федотова Балтач районындагы «Дуслык» хуҗалыгында эшли.

– Әлеге конкурс ярдәмендә мин Хорватиядә булып кайттым. Бу минем чит илгә беренче сәяхәтем иде. Машина белән сыер саву операторы хезмәте яшьләр өчен кызыклы эш түгел. Шуңа безнең өчен республика тарафыннан игътибар аеруча кадерле. Үземне, сәләтләремне күрсәтү генә түгел, үз һөнәрем белән горурлану мөмкинлеге өчен дә рәхмәтлемен, – диде ул.

Бала нигә ботка ашамый?

Бала булган һәр йортта диярлек бер проблема бар – аны ашату. Берсеннән-берсе үзсүзле, берсеннән-берсе көйсез бүгенге заман балалары ашауга да бик талымчан һәм бик нәзберек.

pixabay.com

Шагыйрь әйткәнчә, «әби дә биеп торсын, бабай да көләп торсын» белән генә канәгатьләнми әле алар. Аш, ботка ише ризыкларны ашату өчен кимендә атказанган артист булырга, психолог, невролог һәм тагын башка күп кенә һөнәрләрнең нечкәлекләрен тирәннән белергә кирәк. Тик заманда һәм балада гынамы соң гаеп? Шушы арада булган бер вакыйга бу хакта уйланырга мәҗбүр итте.

Танышымның Казанда яшәүче ике яшьлек оныгы да башка сабыйлардан аерылмый. Бик хәрәкәтчән, бик актив булса да, ашавы әллә кем түгел. Теләгәнен ашый, теләмәгәнен – юк. Аны ничек ашатканнарын күреп, янәшәдәгеләренең сабырлыгына соклана торган. Менә шул сабый күптән түгел бераз авырып алды. Анализларның бер-икесен ач карынга тапшырырга һәм УЗИ үтәргә кушканнар. Соңгысы да ач карынга һәм язылу буенча сәгать унга гына барасы. Ни хикмәт, үч иткәндәй, таң белән торып утырган баланы сәгать унга кадәр ашатмыйча түздерү аны мәҗбүри ашатудан да авыррак булып чыккан.

– Башка көнне ашауда гаме булмаган кебек тоелган улыбыз торуга ук ашарга сорый башлады, – дип сөйли әбисе. – Ике яшь кенә булса да, теле иртә ачылды, барысын исемләп әйтә. Табиблар кичке алтыдан соң ашатмаска кушкач, анализлар дөрес чыксын дип, алар әйткәнне тыңлаган идек шул. Күрәсең, эче тәмам бушаган. Башта гадәт буенча кете-мете: печенье-конфет сорап алҗытты. Аннан, берне генә, кечкенәне генә бир инде, дип ялына башлады. Әле суыткычка алып бара, әле шкафка. Өзми дә куймый: «Шунда бар бит инде, бир», – ди. «Шкафка буем җитми», – дип котылмакчы идем, табуретка өстерәп килде, шушында бас, ди. Башка әйбер бирмәгәч, ипи бир, ди башлады. Күз яшьләре белән сорый балакаем… Нәрсә бирсәң дә ашыйсы… Менә, мин әйтәм, берни ашамый торган бала! Уенда да гаме юк, телевизор да, планшет та, телефон да кирәк түгел. Башка чакта аерып алып булмый торган мультиклары белән дә алдап булмады. Уенда да, телендә дә бары тик ашау гына. Көч-хәл белән тиешле сәгатьне көтеп җиткердек. Инде түзәр хәл калмады, поликлиникага вакытыннан алдарак барыйкмы әллә дә дигән идем, анда да шул безнең кебек ач килгән балалар бит, дип кенә сабыр иттек. Белгән булсак, аны башка көнгә, иртәнге сәгатькә үк яздырган булыр идек тә… Ашауга исе китми, аппетиты да юк дигән идек шул… И Раббым, ачлыклар күрсәтмә, дидем азактан. Бүгенге балалар ачлыкка түзә ала торган балалар түгел. Безнең әбиләр, әниләр тегe заманда ни хәлләр чыдады икән дә ач сабыйларны ни хәлләр үстерделәр-түздерделәр икән, дидем…

Ә без үзара, балаларны ашатып булмый, дип зарланышабыз. Билгеле, йокларга ятканчы кулыннан баллы тәм-том өзелмәгән, әле согын эчкән, әле җиләк-җимеш, яшелчә кимергән бала солы боткасын да, токмачлы ашны да теләр-теләмәс кенә ашар шул. Үтеп китешли төрлесеннән бер-ике капкан әнә шул «тәмнүшкә»ләр хисабына аппетиты бозылуын да өстәсәң, аптырыйсы да калмый бугай. Бәлки, ялгышамдыр. Әйдәгез, бер генә көн танышларым кебек бушану сәгатьләре үткәреп карагыз әле…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Үзебезнекен сайла

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

«Татар-информ»

Татар халкын берләштерү, туган телне киңрәк кулланышка чыгару. «Хатлар йорты» проекты авторы Энҗе Садыйкова татарча котлаулар проектының төп миссиясе әнә шул ди. Күптән түгел тәбрикләмәләрнең яңа коллекциясе тәкъдим ителде.

Рәссамнар белән эшләнгән яңа коллекция ике җыелмадан тора. «Туганлык җепләре» дип аталганы гаилә темасына багышланган. Әлеге җыелмада 15 ачык хат. Иллюстраторы – Лилия Гәрәева.

– Туганнар, гаилә темасы безнең өчен аерым бер әһәмияткә ия. Гомумән, йорт, гаилә, нәсел, нигез – татарның төп төшенчәләре. Безнең тәбрикләмә, ачык хатлардан да иң күбе шуларны сорыйлар һәм алалар, – дип сүзен дәвам иттерде Энҗе Садыйкова.

Икенче җыелма – шаян открыткалар. Ул «Кара дуслар» – Татарстан тормышы һәм татар теле турында кызыклы контент иҗат итүче популяр медиапроект белән уртак җыелма. Юморга таянып иҗат ителгән ачык хатларны кәеф күтәрү өчен якыннарга, дусларга биреп була.

– Бу серия дә безнең өчен бик мөһим, чөнки без башлап җибәргәндә үк юморга басым ясап эш иттек. Халык та бу юнәлешне бик яратты, – ди Энҗе.

Проект авторы сүзләренчә, «Хатлар йорты»ның төп бурычы – туган телне куллану даирәсен арттыру.

– Тел, мәдәният аша милләткә мәхәббәт уяту максатын да күздә тотып эшлибез. Аннан һәр кеше дә сүз остасы түгел. Безнең тәбрикләмәләр һәм ачык хатлар ярдәмендә кеше үзенең якынына күңелендә булган ихлас сүзләрне җиңелрәк итеп җиткерә, – диде ул. – Без 8 елдан артык эшлибез. Вакыт узган саен кешене шаккатыру бик авыр. Елдан-ел авыр, әмма шуның белән кызык та.

Соңгы ике ел эчендә барлыгы 36 мең открытка бастырылган. Аның 23 мең ярымы сатылган.

– Открытка ул – су да, ризык та, кием дә, көнкүрештә бик кирәк булган әйбер дә түгел. Бер караганда, ансыз да яшәп була. Әгәр кеше шундый зур саннарда ала, кызыксына икән, димәк, халыкка кирәк, тел дә исән, – диде Энҗе Садыйкова.

«Хатлар йорты» мөселман темасына багышланган серия, ретро-хатлар, Казан фотографияләре, җырлы хатлар серияләрен дә әзерләгән.

– Ретро-хатлар сериясенең текстларын әнинең яшь чагындагы куен дәфтәреннән алдым. Элек хат язганда яңа сүз уйлап тапмас өчен, җор, кызык сүзләрне язып барганнар. Шигъри формада да, хат рәвешендә дә булган. «Казаннан хатлар»да шәһәр фотосурәтләре бирелгән. Быелгы туристик сезонда андый открыткаларны 2 меңнән артык саттык, – ди проект авторы. – 8 коллекция арасында иң үзенчәлеклесе – «Ак барс» хоккей клубына бәйле ачык хатлар. Монда хоккей тормышыннан төрле күренешләрне керттек, әлеге спорт төренең фәлсәфәсен чагылдырдык. Алар белән кызыксыну аеруча зур.

Башка төбәкләрдә яшәүче татар кешеләре белән хат алышып карыйсы килгән кеше моны «Хатлар йорты»ның посткроссинг сервисы аша эшли ала. Моның өчен «Миллиард.татар» порталына кереп, теркәлү узарга кирәк.

Ләйсән САФИНА

СЫНАТМАСЫН ЙӨРӘГЕҢ

Кан басымын кайчан үлчәп, даруыңны кайчан эчәсен телефон искә төшереп тора. Татарстанда әнә шуны күздә тоткан «Элемтә» сәламәтлекне күзәтү сервисы эшләп килә.

Әлеге кушымтаны телефонга йөкләтергә мөмкин. Ул йөрәк-кан тамыры авырулары булган кешеләргә сәламәтлеген контрольдә тотарга, табиб белән онлайн рәвештә элемтәдә торырга ярдәм итә. Әлеге проектның җитәкчесе Вадим Шитов сүзләренә караганда, бүген Татарстанда бу кушымтадан барлыгы 15 меңнән артык кеше файдалана.

«Инсульт, инфаркт кичергән кеше сәламәтлеген даими рәвештә контрольдә тотарга, кан басымын, кандагы шикәр күләмен үлчәп торырга тиеш. Махсус мобиль кушымта исә аларны вакытында башкарырга кирәген искә төшереп тора, соңрак шуларның нәтиҗәләрен автомат рәвештә табибка юллый», – ди Шитов.

Заманча телефоннан файдалана белмәгән өлкәннәргә исә МКДЦ, Республика клиник хастаханәсе, 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсе белән КФУның медицина-санитария частенда эшләп килүче кардиология бүлекләрендә махсус кәгазь конверт тапшырыла. Алар шушы бүлектә ятып, дәваланып чыккан кешеләргә бирелә. Шул рәвешле өлкәннәр сәламәтлегендәге үзгәрешләрне кулдан да теркәп бара ала.

Хәтерләсәгез, Татарстанда уйлап табылган әлеге «Элемтә» сервисы Россиянең иң яхшы инициативалары арасында 13 нче урынга чыккан иде. Баштарак йөкле хатын-кызларның сәламәтлеген контрольдә тотуны күздә тоткан әлеге кушымтадан хәзер йөрәк-кан тамыры авыруларыннан интеккән кешеләр дә файдалана ала.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш кардиологы Зөлфия Ким сүзләренә караганда, йөрәк-кан тамырлары авырулары әле дә булса үлем-китемгә китергән чирләрнең беренче өчлегендә кала бирә. Авыруларның үз сәламәтлегенә салкын каравы хәлне тагын да мөшкелләндерә, ди белгеч.

– Инсульт, инфаркт кичергән кеше еш кына табиб әйткәннәрне хастаханәдән чыгуга ук оныта. Истә тоткан очракта да аларны үтәргә вакыт тапмый. Көндәлек тормышта аның сәламәтлек белән бәйле күп кенә башка сораулары да туарга мөмкин. Авыруның сәламәтлеген дистанцион рәвештә контрольдә тотарга ярдәм итүче әлеге хезмәт иң беренче чиратта әнә шул ягы белән отышлы. Көчле авырудан соң табиб кушкан киңәшләрне үтәү үлем-китемгә китергән өзлегү очраклары ихтималын 39 процентка киметә, – ди Зөлфия Ким.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Илдар Мөхәммәтҗанов

Адәм баласы

Язучы фикере

Үземә карыйм да кешедәге ахмаклыкка шаккатам.

Премия бирделәр бер көнне. Калын гына конверт, шул юан конверт эчендә – әллә ничә котлау хаты һәм зифа буйлы саф бер купюра. Шатландым инде, әллә ни зур булмаса да, сатып алган акча түгел бит. Аның каравы, кибеткә кергәч, сатучы кызның тиешле купюралары булмады да тегене унлыклар белән бирде. Менә, җәмәгать, акчаның үз сере бар икән аның. Галәмәт әйбәт эшли. Тылсым! Акчаңны күбәйтәсең килсә, аны унлыкка әйләндерергә кирәк икән. Вәт шунда күбәя дә, весы да арта.

Бөтен кесәләр көнбагыш тутырган кебек кабарып чыкты хәзер. Кесәгә сыймаганын учка йомдым. Китеп барам шулай шалтыратып урам буйлап. Бөтен нәрсә кабарган, йодрык йомарланган. Базарга җиттем. Бер читтәрәк теләк теләп озатучылар тезелеп баскан. Хәер биреп китсәң – теләк телиләр, бирмәсәң – озатып калалар. Кая икәнен белмим. Тыңлап бетерәсеңмени инде аны. «Иди ты...» – диләр инде. Озаталар.

Менә ул, җәмәгать, йодрык төйнәп йөрүдән дә авыррак нәрсә юк икән. Уч кычыта башлый. «Татарлар, бердәм булыйк, бер йодрык булыйк!» – дигән чакыру бар бит әле. Без дә шуңа ышанып, бер йодрык булып бердәмләшәбез дә бераздан кычытына башлыйбыз бугай – таралабыз. Озак вакыт йодрык булу мөмкин түгел икән. Менә шундый акыллы уйлар килә башка. Акыл да акчасы күп кеше янында йөри икән.

Тукта әле, мәйтәм, бер йодрыкны азат итим әле. Әрвахлар рухы да шат булыр, минем премия хөрмәтенә банкет сыман нәрсә ясарлар. Хәер таратырга булдым. Бер картка бирдем – битен сыпырды, икенче кортка чукынырга тотынды, үземне дә чукындыра башлаган иде, өченчесенә күчтем. Киләм шулай рәт буйлап. Рәхәт.

Йөзләренә карамыйм хәзер. Биргәннең битенә карама, дигән әйтем бар бит. Алганның да битенә карарга ярамый икән. Битлеге селкенә башлый. Мин дә карамыйм. Квартира өчен алалар, утка, суга, газга, һавага... Салымнар алалар... Пенялар, процентлар... Алалар, Аллага шөкер. Ихтыяҗ бар. Йөзләренә карамыйм. Бу юлы да шулай. Бер мәлне унлык сузган кулымны берәү бәреп җибәрде.

Башымны күтәреп карасам – корсагын киереп, төп кебек юан бер абзый басып тора. Затлы костюмнан. Галстугының очы минем күкрәккә төбәлгән.

– Син нәрсә мине мыскыл итәсең?! – ди.

– Хәер бирәм, – мәйтәм.

– Мин хәерчегә охшаганмынмы?! – ди.

Ә мин... Нәрсә әйтергә дә белмим. Хәзер кешенең киеменә карап кына бер нәрсә дә әйтеп булмый. Әле бер көн кибеттә бик сәләмә киенгән берәү әллә ничә шешә аракы алды. «Бомжлар банкет үткәрә микән әллә?» – дип артыннан чыккан идем, фәлән миллионлык «Мерседес»ка кереп утырды. Шуңа ни әйтергә дә белми торам.

– Кем белә инде, мәйтәм, бәлки кредитка алгансыңдыр.

– Кредитка! – Теге кызарынды-бүртенде, шартласа – күмелеп калам бит дип үземне кызганып җиргә тартылып куйдым. – Син беләсеңме минем кем икәнне?!

– Юк, белмим.

– Мин – Фәлән Фәләневич Фәләнев!

– Танышуга шатмын. – Фәстердем инде аз гына. Мин танышуга түгел, аның шартламавына шат идем.

– Бу базарның хуҗасы.

Нәрсә дип әйтәсең инде?! Кабат хәер биреп тә тормадым. Оҗмахка кермәячәге көн кебек ачык инде. Ул моны үзе дә беләдер, шуңа хәер-догага исе китмидер. Белә, кәнишне. Бу хәтле гәүдә белән оҗмах ишегенә сыеп буламыни!

Теге бер генә ым какты, ике әзмәвер ике ягымнан тотып базардан чыгарып ташладылар. Кесә тулы тимер акча булгач, авырлык ярыйсы гына арткандыр инде, бик еракка ыргыта алмадылар. Рәхәт инде акчаң булгач. Ул саклый һәр очракта да.

Күп вакыт үтмәде, теге Фәлән Фәләневичнең вафаты турында хәбәр булды. Йөрәге тоткан. Әле менә шуның рухына хәер биреп чыгып киләм. Таныш бит инде. Теге вакытта күңелемә ятмаса да – адәм баласы. Бәлки, бүген аның турында уйлаучы да юктыр. Һәркем үз дөньясында гына хуҗа, башка дөньяга күчтеңме – барысы да башкачарак.

Адәм баласы әллә нәрсәләрнең хуҗасы булырга мөмкин, тик үз гомеренә генә тулысынча хуҗа түгел. Үзеңне әллә кемгә санап, кеше алдында текә кыланырга телисең икән, һич югында ике гомерең булырга тиеш. Ә хәер жалкы түгел... Ул миндә әллә күпме хуҗаларга җитәрлек әле...

Марат КӘБИРОВ

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның
беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

2 КВИТАНЦИЯ
КҮЧЕРМӘСЕН
БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

5–15 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр

П2435
җомга саны
гадәти бәясе ~~512 сум 70 тиен~~
444 сум 54 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
гадәти бәясе ~~1143 сум 96 тиен~~
980 сум 10 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

СЫҢАР КУЛ КӨЧЕ

88 яшькә кадәр сыңар кулы белән өен утын ягып җылыткан ул. Кукмара районының Камышлы авылында яшәүче Нурсанә Шәйхетдинова ике ел элек кенә әлеге мәшәкатьтән котылган. Ялгыз карчыкны авылдашлары ярдәменнән ташламый. Аның теләге кабул була, диләр.

Нурсанә апаның тормышы җиңел булмаган, хәзер дә күз яше түкмәгән көне юк. Ничек чыдаганбыз, дип, күбрәк үткәннәрне искә төшереп елый. Бәхетсезлегенең башын әтисезлектән күрә. Әти-әнисе тумышы белән Камышлы авылыннан. Яшь гаиләне Донбасска вербовкага җибәрәләр. 1941 елда әтисе сугышка китеп, хәбәрсез югала. «Өч көн вакыт бирәбез, йә кайтып китәсез, йә шунда үләчәксез», – дигәч, Шәйхетдиновлар туган якларына кайту ягын карый. Әнисе Галиянең кочагында – 4 бала, өстәвенә бишенчесенә көмәнле. Поездда 16 көн кайталар.

– Донбасста җиләк-җимеш ашап, рәхәттә яшәргә өйрәнгән идек. Авылга кайтып төпләнгән елларның михнәтен мәңге онытмыйм. Яшәргә урыныбыз булмагач, Камышлыда өйдән-өйгә йөрдек. Алты йортта тордык, подвалда да яшәдек. Идән урынында – балчык. Өскә ябынырга – юрган, баш астына салырга мендәр дә юк. Үзебез белән алып кайткан табак-савытлар гына бар. Өйне салам ягып җылыттык. Ашарга ризык, киенергә кием юк. Шул елларда 2–3 яшьлек туганнарым үлде. Өстәвенә Харис энебез дә телсез, – дип әрнеп искә алды Нурсанә апа.

Әнисе 54 яшендә коймак пешергәндә йөрәк өянәгеннән егылып үлә. Шуннан соң әнисенең сеңлесе, балаларны карар өчен, Кукмарадан авылга кайта. Эшеннән ярдәм сорап, якыннары өчен йорт төзетә. Бары шунда гына үзләренең куышы була. Апасы үлеп киткәч, таякның авыр башы

Нурсанәгә төшә. Сыңар кулы белән тормыш көтә. Ә кулын 13 яшьлек чагында өздерә.

– Сентябрь ахыры. Бәрәңге өшемәсен дип, шуны урнаштырып йөри идем. Ындыр бригадиры өйгә килеп, эшкә чыгарга кушты. Ул вакытта комбайннар юк. Атлы машина ярдәмендә көлтәдән ашлыкны аера идек. Саламны эткәндә, кулым тимергә эләгеп өзелде. Ул вакытта, яфрак ашап, каян көч булсын соң?! – ди Нурсанә апа.

Менә шуннан бирле (77 ел. – **Автор**) тормышны бер кул белән алып барырга өйрәнә. Бервакытта да зарланып утырмый. Терлекләр, каз-чебешләр асрый. Бәрәңгесен, яшелчәсен үстерә. Бакча казый, бәрәңге төбен өя, уңышын җыя. Чиләк-көянтә белән су ташый. Моннан тыш, эшкә дә барасы бар. Утыз ел буе клубта идән юа, лом белән боз вата, балта белән утын ярып, мич җылыта. 64 яшькә кадәр энесе Харисны тәрбияли. Аны юындыра, киендерә. Авыл халкы аның көченә әле дә шакката. Барысына да шушы бер кулның көче ничек җиткән?! Хәзер инде кул-аяклары сызлап интектерә икән.

Нурсанәнең дә башкалар кебек сөясе, сөеләсе килсә дә, юк, дип йөрәгенә кырт кисә. «Тәкъдим ясасалар да, сыңар кул белән кая барасың? Балаң булыр... Иргә хезмәт итәргә кирәк. Барысын төптән уйладым. Хәзер минем яшьтәгеләр оныклар, оныкчыклар сөя», – ди ул.

Бүген Башкортстанда яшәүче Җәүһәрә сеңлесеннән башка бер туганы да калмаган. Ул авырый, монда кайтып йөри алмый икән. Әле ярый игелекле авылдашлары бар. Социаль хезмәткәр Фирания Арсланова мунча кертә, керләрен юа.

– Рафия исемле бик әйбәт күршем бар. Көн саен кереп: «Йоклый алдыңмы, даруыңны эчтеңме?» – дип хәл белешә. Бәрәңге әрчеп бирә. Бүген ике тапкыр керде инде. Авыл кешесе бәрәңге, яшелчә, җиләк-җимешләрне гошер итеп бирә. Бәрәңгене быел утыртудан туктадым. Әнә Зөлфия ике капчык бәрәңге алып килде, – дип авылның изге җанлы кешеләрен саный Нурсанә апа. – Газ кергәнгә – ике кыш. Аңа кадәр мичкә үзем яктым. Күршеләр чыра телде, көлне алды. Илдарханның кече малае бик рәхимле. Бөтен яшьләрне җыеп, түбәдән кар төшерә, капка төбен трактор белән чистарта. Бер тиен акча алмыйлар, артларыннан елый-елый рәхмәт әйтәм.

Нурсанә апа язмышына үпкәләми. Сынауларны Аллаһ биргән, димәк, шулай кирәк булган дип кабул итә. Ә менә телевизордан Украинага бәйле хәбәрләрне караган саен яралары тагын кузгала. «Ничек туган якларыбызга вакытында кайтып калганбыз. Ул вакыттагы ядрәләр тавышы колакта һаман чыңлап тора. Без әти рәхәтен күрмәдек. Башка сабыйлар безнең кебек бәхетсез булмасын иде. Ялварып кылган догам шул», – дип озатып калды ул безне.

Сәрия МИФТАХОВА

БУЛАТ КАБАТ КАЙТКАН!

«Зәңгәр шәл»дәге Булат белән Мәйсәрә мәхәббәтенә кемнәр генә сокланмады икән? Моннан бер гасыр элек язылган әлеге пьеса инде күптән татар театрының классикасына әйләнде. Казан шәһәр филармониясе исә, җырлы-биюле яңа төсмерләр өстәп, барыбызга да таныш булган әсәрне кабат искә төшерде.

Премьерасы 16 ноябрьдә үк булган тамашаны узган атнада без дә күреп кайттык. Төп рольләргә, ягъни Булат белән Мәйсәрә роленә Рөстәм Насыйбуллин һәм Сәйдә Мөхәммәтҗанова сайланган. Рөстәм Насыйбуллинны Кәрим Тинчурин әсәрен укыганда күз алдына килеп баса торган Булатның прототибы диярсең. Шундый ук көр тавышлы, кыюлыгы йөзенә чыккан. Сәхнәдә үзен җиңел тотуы героена хас ирек сөючәнлеккә ишарә итә.

Мәйсәрә роленә ике актриса билгеләнгән, тагын берсе – Гөлназ Гафурова. Без Гөлназ-Мәйсәрәле тамашаны карадык. Җырлы-биюле спектакльдә филармония солистлары: Татарстанның халык артисты Фердинанд Фәтхи, Татарстанның атказанган артистлары Гөлшат Имамиева, Эльвира Хәйруллина, Айдар Габдинов, Ләйсән Мәхмүтова, Фәридә Әхмәтшина, Марина Карпова, Алсу Сөнгатуллина, шулай ук Айзат Мәрдан, Гөлнара Мулланурова, Илнур Фәсхетдинов, Алмаз Хәсәнов һәм данлыклы «Казан» бию ансамбле дә катнаша. Сәнгать җитәкчесе – Татарстанның халык артисты Чулпан Закирова.

Пьеса шактый кыскартылган, кайбер өлешләрдә үзгәрешләр дә ишетелде. Текстны заманга яраклаштырасы иткәннәр, ахры. Заманча элементлардан арткы пландагы экранны да бик оста кулланганнар иде. Нәтиҗәдә, декорациянең бөтенләй дә кирәге булмаган. Сәхнәдәге күренешләр белән беррәттән экранның да «кәеф»е үзгәреп торды.

Җырчыларга, дөресрәге, актерларга килгәндә, араларында, күргәнегезчә, театр һәм кино өлкәсендә дә тәҗрибәсе булганнар бар. Ләкин кайберләре «Зәңгәр шәл»дә бөтенләй яңа яктан ачыла. Әйтик, хатын алып туймаган ишан ролендәге Фердинанд Фәтхинең үзе өчен дә бу роль яңалык булгандыр.

Ә аның хәләл җефетләрен уйнаган Ләйсән Мәхмүтова, Фәридә Әхмәтшина, Алсу Сөнгатуллина, Марина Карпова тамашаның туйганчы көлә торган өлеше өчен җаваплы иделәр. Биюләре бу эффектны арттырды гына. Шуңа өстәп, геройларның холкын ачарга да ярдәм итте.

Биегән кеше кем була?

Гомумән алганда, шәһәр филармониясе тәкъдим иткән «Зәңгәр шәл»дә бию үзе аерым бер роль уйнады. Сүз һәм җыр белән генә әйтеп-аңлатып бетерә алмаган хисләр биюгә салынган иде. Гөрләп торган Сабан туе мәйданындагы күңел ачулар да, Мәйсәрәнең ишан хатыны булгач боегып утырулары да, качкыннарның кыюлыклары да хәрәкәтләр аша күрсәтелде. Аеруча соңгысы – «Казан» бию ансамбле егетләренең кыюлык, гаярьлек һәм кара урманда көн күрүче качакларның бирешмәс рухы белән сугарылган биюләре истә калды. Хәер, ул биюне башка концертларда да күрергә туры килгәләде.

Костюмнар турында да бер-ике кәлимә сүз әйтергә кирәктер. Җырлы-биюле спектакльдә катнашучыларның өс-башларында «документальлек» чалымнары күренмәде. Ягъни баена, ярлысына карап тормыйча, барлык геройлар затлы-зәвыклы костюмнардан иде. Бу аңлашыла да инде: заманча куелыш икәне алдан әйтелде бит. Тик, нинди генә матур киемнәрдән булмасыннар, геройларның тышкы кыяфәте каршылык тудырды.

Шулай итеп, Казан шәһәр филармониясе репертуарында «Зәңгәр шәл»нең эчтәлек ягыннан җиңеләйтелгән, хәрәкәтләр теле ягыннан баетылган варианты пәйда булды. Тамашачысын табармы ул, озын гомерле булырмы – анысын вакыт күрсәтер.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 385

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+